**ГЛАВА**
**Кучуковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Көчек авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ    КАРАР

08.11.2022    Түбән Көчек авылы    № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Рус Шаршадысы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е :

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Рус Шаршадысы торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 24 ноябрендә 14 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Рус Шаршадысы торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Рус Шаршадасы торак пунктында Полевая урамы буенча юлларны кардан чистарту.

2. Рус Шаршадасы торак пунктының Полевая урамында юлны карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, грейдерлау.

3. Суэтем башнясын тоту (хезмәт күрсәтү, тирән насос һәм башка материаллар сатып алу, хезмәт килешүе буенча суэтем башнясы хезмәткәренә хезмәт хакы түләү).

4. Урам утларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Рус Шаршады авылы, Луговая урамы, 17А, ИП Закирова “Карлыгач” кибете янында уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Нурмөхәммәтов